МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.11.2025 Казан ш. 4064-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын бетерү һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында» 19.12.2015 № 3233-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында», 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «СК «ГАЗЖИЛСЕРВИС» ҖЧҖ документациясенә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендә газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналарын билгеләү турында» 19.12.2015 № 3233-р карары (алга таба - № 3233-р Карар) белән урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендәге, «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендәге 16:50:090313:380 кадастр номерлы

җир кишәрлекләрендәге инвентарь номеры 18893, реестр номеры 16:50-6.2633 булган бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын газүткәргеч сүтелү сәбәпле бетерергә. Газ бүлү газүткәргеченең саклау зонасы гомуми мәйданы 980 кв.м.булып, 245 м озынлыкны тәшкил итә.

2. Территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар чикләре урнашуның текстлы һәм график тасвирламасында күрсәтелгән белешмәләргә, газүткәргеч чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге нигезендә № 3233-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 24.01.2017 № 107-р, 22.06.2017 № 1378-р, 13.07.2017 № 1608-р, 29.08.2017 № 1977-р, 28.09.2017 № 2191-р, 22.09.2017 № 2155-р, 22.08.2018 № 2563-р, 31.08.2018 № 2653-р, 05.12.2018 № 4140-р, 25.06.2019 № 1970-р, 07.08.2019 № 2419-р, 05.11.2019 № 3520-р, 21.01.2020 № 117-р, 25.10.2021 № 3236-р, 28.12.2021 № 4111-р, 14.06.2022 № 1741-р, 22.08.2022 № 2447-р, 05.07.2023 № 1849-р, 06.12.2023 № 3416-р, 14.03.2024 № 621-р, 17.04.2024 № 1078-р, 23.10.2024 № 3353-р, 27.11.2024 № 3845-р, 27.02.2025 № 659-р, 27.02.2025 № 658-р, 14.03.2025 № 807-р, 19.03.2025 № 877-р, 02.04.2025 № 1051-р, 11.07.2025 № 2339-р, 15.07.2025 № 2391-р, 30.09.2025 № 3478-р) карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Казан ш. (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары) территориясендәге 1452,29519 км озынлыктагы, ЭПУ «Казаньгоргаз»ның әлеге карарның 1 нче кушымтасында күрсәтелгән инвентарь номерлы газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләр) 5,44029684 кв.км мәйданны тәшкил иткән саклау зоналары чикләрен «Рубикон» кадастр үзәге» ҖЧҖ, «РКЦ «Земля» АҖ, «Күчемсез милек кадастры» ҖЧҖ, «ГеоПроект» ҖЧҖ, «Казан ш.нең җир-инвестиция агентлыгы» ҖЧҖ, «АллЮр» ҖЧҖ, «Основание» кадастр үзәге» ААҖ, «Бәяләү һәм кадастр үзәге» ҖЧҖ, «КАДАСТР» ҖЧҖ тарафыннан әзерләнгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зоналарына картасында (планында) булган белешмәләр нигезендә урнаштырырга.»;

1 нче кушымтада инвентарь номеры 18893 булган газүткәргечкә туры килгән 261 нче юлны төшереп калдырырга һәм «Барысы» юлында «1452540,19» цифрларын «1452295,19» цифрларына алыштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**